**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2026 елның 4 сентябрендәге 3099 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2026 елның 30 июнендәге 2231 номерлы**
**«Шәһәрнең гомуми файдаланудагы территорияләрендә**
**су басуны булдырмау өчен Казан шәһәренең яңгыр сулары**
**канализациясен карап тоту һәм ремонтлау чыгымнарын каплау**
**максатыннан оешмаларга Казан шәһәре муниципаль берәмлеге**
**бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында»гы**
**карарына үзгәреш кертү хакында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78 статьясы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2023 елның 25 октябрендәге 1782 номерлы «Юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә, шулай ук товар җитештерүче, эшләр башкаручы, хезмәтләр күрсәтүче физик затларга Россия Федерациясе субъектлары бюджетларыннан, җирле бюджетлардан субсидияләр, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантлар бирүне һәм күрсәтелгән субсидияләрне, шул исәптән субсидияләр рәвешендәге грантлар алучыларны сайлап алуны уздыруны җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләрне раслау турында»гы карары нигезендә, шулай ук юридик-техник характердагы җитешсезлекләрне бетерү максатыннан **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2026 елның 30 июнендәге 2231 номерлы «Шәһәрнең гомуми файдаланудагы территорияләрендә су басуны булдырмау өчен Казан шәһәренең яңгыр сулары канализациясен карап тоту һәм ремонтлау чыгымнарын каплау максатыннан оешмаларга Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында»гы карарына, 1 пунктта «расларга һәм 2026 елның 1 гыйнварыннан гамәлгә кертергә» сүзләрен «расларга һәм йогынтысы 2026 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә» сүзләре белән алмаштырып, үзгәреш кертергә.

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.В.Куляжевка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**